**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«06» апрель, 2021 ел № 224

Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2021 елның 2 кварталына салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен раслау турында

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Россия Федерациясе Торак коды, 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законы һәм һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен билгеләү методикасы, һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителергә тиешле салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы нигезендә, «Россия Федерациясе буенча торак урыны гомуми мәйданы бер квадрат метрының нормативын һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясен

билгеләү методикасынраслау турында»гы 2013 елның 5 мартындагы 66/ГС номерлы Дәүләт төзелеше (Госстрой) боерыгы белән расланган методикадан файдаланып, «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2021 елның 12 февралендәге 48 номерлы «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» коммерцияле булмаган партнерлыгының хатына, Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының 2021 елның 2 кварталына уртача базар хакы күрсәткечләре турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2021 елның 26 февралендәге 94/пр боерыгына таянып, Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Гражданнарны наем шартнамәсе буенча торак урын бирелүгә мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен максималь күрсәткечләр билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 601 490 сум

1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 2 038 260 сум

1.1.3. Өч кешелек гаилә өчен - 2 620 620 сум

1.1.4. Дүрт кешелек гаилә өчен - 3 494 160 сум

1.1.5. Биш кешелек гаилә өчен - 4 367 700 сум

1.1.6. Алты кешелек гаилә өчен - 5 241 240 сум

1.1.7. Җиде кешелек гаилә өчен - 6 114 780 сум

1.2. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган айлык уртача җыелма керемнең максималь күләме:

1.2. Максимальный размер среднемесячного совокупного дохода, приходящего на каждого члена семьи:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен - 20 983 сум

1.2.2. Ике кешелек гаилә өчен - 13 353 сум

1.2.3. Өч кешелек гаилә өчен - 11 446 сум

2. Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында

күрсәтелгән максималь күләмнәрдән файдаланырга, наем шартнамәсе буенча торак урын бирелүгә мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Муниципаль район
башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Хәбибуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА